**ИСПОЛКОМ АПАСТОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422350, пгт. Апастово, улица Советская, д.2

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

422350, штп. Апас, Советская урамы, 2 йорт

тел.: (84376) 2-13-52, факс: 2-19-27, e-mail: apast@tatar.ru, http://apastovo.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

№ 316 от 14.10.2021

**Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы территориясе буенча гомуми файдаланудагы автомобиль транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру тәртибенә үзгәрешләр кертү турында**

«Халыкара автомобиль йөртүләрен гамәлгә ашыруга дәүләт контроле турында һәм аларны үтәү тәртибен бозган өчен җаваплылык турында» Федераль законның 2 һәм 6 статьяларына һәм «Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» Федераль законга үзгәрешләр кертү турында» 2021 елның 2 июлендәге 337-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы башкарма комитеты **карар итте:**

1.Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 2 апрелендәге 69 номерлы карары (Апас муниципаль районы Башкарма комитетының 2013 елның 24 маендагы 101 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Татарстан Республикасы Апас муниципаль районы территориясе буенча гомуми файдаланудагы автомобиль транспортында пассажирлар һәм багаж ташуны оештыру тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1)1.1 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.1. «Россия Федерациясендә автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында даими рәвештә пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2015 елның 13 июлендәге 220-ФЗ номерлы Федераль закон нигезләмәләрен исәпкә алып әлеге Тәртип даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутларын билгеләү, үзгәртү, туктату буенча мөнәсәбәтләрне (шул исәптән әлеге маршрутларны билгеләү, үзгәртү яисә туктату турында юридик затларның, индивидуаль эшкуарларның, гади ширкәт шартнамәсендә катнашучыларның гаризаларын карау тәртибе, шулай ук әлеге маршрутларны билгеләүдән яисә үзгәртүдән баш тарту өчен нигезләр, әлеге маршрутларны гамәлдән чыгару өчен нигезләрне) җайга сала.»;

2) 1.3 пунктында "Автомобиль транспортында һәм шәһәр җир өсте электр транспортында пассажирлар йөртү кагыйдәләрен раслау турында" Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2009 елның 14 февралендәге 112 номерлы карары белән" сүзләрен төшереп калдырырга;

3)9.4 пунктының беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9.4.Даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршруты картасында түбәндәге белешмәләр күрсәтелә:»;

4)9.4 пунктының 1 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1) даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның маршрут картасын биргән вәкаләтле җирле үзидарә органы исеме.»;

5) 9.4 пунктының 4 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның әлеге маршрутны урнаштыручы вәкаләтле җирле үзидарә органы тарафыннан бирелә торган Тәртип номеры.»;

6) 9.4 пунктының 5 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5) башлангыч тукталыш пунктының һәм даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршруты буенча соңгы тукталыш пунктының атамалары рәвешендә йә чикләрендә башлангыч тукталыш пункты һәм әлеге маршрут буенча соңгы тукталыш пункты урнашкан җирлекләрнең исемнәре рәвешендә даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршруты исеме;»;

7) 9.4 пунктының 10 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10)даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршрутлары реестрына карата әлеге маршрутка карата каралган транспорт чараларына характеристикалар.»;

8) 4.2 пунктының беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4.2.даими рәвештә пассажирлар йөртүнең һәм багаж ташуның муниципаль маршрутлары реестрларына түбәндәге белешмәләр кертелергә тиеш:»;

9) 4.2 пунктының 9 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «9) даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршрутын билгеләү яисә үзгәртү турындагы карар, муниципаль контракт һәм (яисә) ачык конкурста катнашучы тарафыннан бирелгән ачык конкурста катнашуга гариза белән каралган транспорт чараларына (транспорт чараларының төрләре, транспорт чараларының экологик характеристикалары, транспорт чараларыннан файдалануның максималь срогы, пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршруты буенча пассажирлар йөртүне һәм багаж ташуны гамәлгә ашыру турында таныклык бирелә торган транспорт чараларына характеристикалар) характеристикалар”;

10) 4.2 пунктының 10 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«10) даими рәвештә пассажирлар йөртү һәм багаж ташу маршруты буенча файдалану рөхсәт ителә торган һәр классլы транспорт чараларының максималь саны;».

2. Әлеге карар, 2022 елның 1 сентябреннән үз көченә керүче әлеге карарның 1 пунктындагы 8 пунктчасыннан тыш, басылып чыккан вакыттан үз көченә керә.

3.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http:pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

**җитәкче** **А.А. Тугушев**

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АПАСТОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АПАС МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
ОБЩИЙ ОТДЕЛ
ГОМУМИ ОТДЕЛ